КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1320

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел,

24 апрель, 281 нче; 2018 ел, 14 июнь, 481 нче; 2018 ел, 17 октябрь, 940 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлекнең 1 пунктындагы 1 пунктчаның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«өченче төркем – халык саны 250 мең кешедән 500 мең кешегә кадәр булган муниципаль берәмлекләр, муниципаль районнар, үзәкләре шәһәр округларында урнашкан административ үзәкләр;».

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән 10 көннән соң үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин